СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 321 10.09.2015
№ _________от _____________

# КАРАР

«Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге турында нигезләмә хакында» 2006 елның 06 мартындагы 50 номерлы Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр мониторингының дини һәм милли туфракта конфликтларны иртә кисәтүнең комплекслы системасы турында» 2015 елның 25 апрелендәге ПУ-414 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге турында нигезләмә хакында» 2006 елның 06 мартындагы 50 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 пунктын түбәндәге эчтәлекле 2.10 - 2.13 пунктчалары белән тулыландырырга:

«2.10. милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, җирлек территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклап калуга һәм үстерүгә, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясенә, милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру;

2.11. милләтара һәм конфессияара килешүне ныгытуга, муниципаль район территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен үстерүгә, җирле аз санлы халыкларның һәм башка милли азчылыкларның хокукларын тормышка ашыруга, мигрантларның социаль һәм

мәдәни җайлашуын тәэмин итүгә, милләтара (этносара) конфликтларны профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны эшләү һәм гамәлгә ашыру.

2.12. муниципаль район территориясендә җирле милли-мәдәни автономияләрнең хокукларын гамәлгә ашыру белән бәйле эшчәнлекне тормышка ашыру өчен шартлар тудыру;

2.13. Россия Федерациясе халыкларының милли-мәдәни үсешенә һәм муниципаль район территориясендә милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыруга ярдәм күрсәтү;»;

1.2. Нигезләмәнең 3 пунктын түбәндәге эчтәлекле 3.21 - 3.24 пунктчалары белән тулыландырырга:

«3.21. милләтара һәм конфессиональара татулыкны ныгытуга, район территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклап калуга һәм үстерүгә, мигрантларны социаль һәм мәдәни адаптацияләүгә, милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалауга юнәлтелгән чараларны тормышка ашыру өчен шартлар тудыра;

3.22. милләтара һәм конфессияара килешүне ныгытуга, муниципаль район территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен үстерүгә һәм аларга ярдәм итүгә, җирле аз санлы халыкларның һәм башка милли азчылыкларның хокукларын тормышка ашыруга, мигрантларның социаль һәм мәдәни җайлашуын тәэмин итүгә, милләтара (этносара) низагларны профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны эшли һәм гамәлгә ашыра;

3.23. муниципаль район территориясендә җирле милли-мәдәни автономияләрнең хокукларын гамәлгә ашыру белән бәйле эшчәнлекне тормышка ашыру өчен шартлар тудыру;

3.24. муниципаль район территориясендә Россия Федерациясе халыкларының милли-мәдәни үсешенә һәм милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыруга ярдәм күрсәтә.».

2. Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә Саба муниципаль районы территориясендә мониторингның комплекслы системасы кысаларында мәгълүматны җыю, саклау, эшкәртү һәм анализлау өчен җаваплы затны урынбасар дәрәҗәсендә билгеләргә һәм вазыйфаи инструкцияләргә тиешле үзгәрешләр кертергә.

3. Саба муниципаль районы Башкарма комитетына Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына мониторингның комплекслы системасы кысаларында мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р.Н. Минниханов